# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Кәрәкәшле торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**23.11.2022 ел** **№ 5**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 22 ноябрендә узган Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Кәрәкәшле торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча сез ризамы, дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмәсе төзелде:

- Кәрәкәшле торак пунктында зират территориясен киртәләүне ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктындагы урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);
- Кәрәкәшле торак пунктында Мирфатих Зәкиев урамында тротуар төзү, (смета буенча: вак ком-таш, асфальт сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, җәю, эш өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында авыллар эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча түләү).»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 544 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 286 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 286 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Кәрәкәшле торак пунктында гражданнарның җыены узган һәм һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип кабул итәргә.
2. Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Кәрәкәшле торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча сез ризамы:

- Кәрәкәшле торак пунктында зират территориясен киртәләүне ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктындагы урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);

- Кәрәкәшле торак пунктында Мирфатих Зәкиев урамында тротуар төзү,

(смета буенча: вак ком-таш, асфальт сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, җәю, эш өчен түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктында җирлек эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча түләү)» сораулары буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев